**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1865**
**16.04.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5858 номерлы карары белән расланган җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5858 номерлы карары (Башкарма комитетның 2015 елның 4 сентябрендәге 4936 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 3281 номерлы, 2017 елның 31 августындагы 5059 номерлы, 2018 елның 2 мартындагы 1053 номерлы, 2019 елның 5 июлендәге 3442 номерлы, 2019 елның 22 октябрендәге 5403 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.4 пунктына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | гариза теркәлгән вакыттан башлап 14 эш көнендә | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясының 6 бүлеге |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов